ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__01.05.2026___ Казан ш. № _205/2026_____

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 31.08.2023 № 565/2023 боерыгына үзгәрешләр кертү турында
«Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты комиссиясе турында»

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актын актуальләштерү максатларында
БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 31.08.2023 № 565/2023 боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 24.05.2024 № 402/2024 боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләрне расларга.
2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 31.08.2023 № 565/2023 боерыгы белән расланган Комиссия составын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).
3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис Р. В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2026 елның 205/2026 № - лы боерыгы белән расланды 01.05.2026

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 31.08.2023 № 565/2023 боерыгы белән расланган дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты Комиссиясе турында нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләр

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия дәүләт органының норматив хокукый акты белән төзелә. Күрсәтелгән акт белән комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, комиссия рәисе, аның урынбасары, сәркатибе билгеләп куела һәм комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

2.2 нче пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары (Комиссия рәисе), Дәүләт комитеты рәисе урынбасары (Комиссия рәисе урынбасары), Дәүләт комитетының юридик бүлеге башлыгы, дәүләт комитетының финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (Комиссия сәркатибе), дәүләт комитетының финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегеннән, юридик бүлектән дәүләт хезмәткәрләре дәүләт комитеты рәисе билгели торган дәүләт комитеты, Дәүләт комитетының башка бүлекчәләре;»;

3.1 пунктта:

«а» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәдә каралган дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләрне дәүләт хезмәткәрләренә бирү турында;»;

«б» пунктчасының беренче абзацында «финанс исәбенә алу, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлеге» сүзләрен «финанс исәбенә алу, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасының икенче абзацында «чыгымнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.2 пунктта:

«финанс исәбенә алу, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлеге» сүзләрен «финанс исәбенә алу, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.;

«финанс исәбе, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлегендә» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегендә» сүзләренә алмаштырырга;

3.11 нче пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес һәм тулы дип билгеләргә;»;

3.31 пунктта:

«финанс исәбенә алу бүлеге, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше» сүзләрен «финанс исәбенә алу бүлеге, кадрлар һәм дәүләт хезмәте» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 31.08.2023 № 565/2023 боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.05.2026 № 205/2026)

**Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Хәбибуллина Лариса Васильевна | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары, комиссия рәисе |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Борисова Лилия Петровна | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Сапожников Дмитрий Аркадьевич | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары |
| Абашева Фәнзия Йосыф кызы | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат, комиссия сәркатибе |
| Трусова Полина Геннадьевна | юридик бүлек башлыгы |
| Әфләтунова Альбина Илдар кызы | юридик бүлек башлыгы урынбасары |
| Хуҗина Гөлназ Марсель кызы | финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең әйдәп баручы белгече |

| | |
|---|---|
| Кадыйрова Хәния Расыйх кызы | А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университетының филиаллар белән эшләү бүлеге башлыгы - КАИ, бәйсез эксперт |
| Мөгинов Руслан Рәфыйк улы | Татарстан Республикасы Рәисе идарәсенең коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча вәкиле |